Республика Татарстан

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕБЭК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20айорт
тел. 45-5-50

e-mail: Kilb.Sab@tatar.ru

« 24» сентября 2018 г. № 20

РЕШЕНИЕ КАРАР

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Килдебәк авыл җирлеге Советының 21.09.2018 №19 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитетының 21.09.2018 №36 “Референдум уздыру инициативасытурында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

– Килдебәк авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
– Туктар авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
– Мәртен авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Заһидуллин